СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода,
422591

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы,
422591

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

26.11.2021 с. Введенская Слобода № 15-84

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Введенский Бистәсе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Введенский Бистәсе авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 10 декабренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Введенский Бистәсе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:
- Введенский Бистәсендә җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын 2021 нче елның 10 нчы декабрендә Введенский Бистәсе авылы, Үзәк урамы, 55 нче йорт адресы буенча урнашкан Мәдәният йорты бинасында үткәрергә..

4. Халык җыенын оештыручы итеп Введенский Бистәсе авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов